УДК 398

***И.И. Ямалтдинов***

# ТАТАР ҖЫРЛАРЫН ӨЙРӘНҮГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР
## (Фольклорчы Илбарис Надировның тууына 100 ел)

Статья посвящена анализу научной и научно-организационной деятельности заслуженного работника культуры Республики Татарстан, лауреата Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая, ученого-фольклориста И.Н. Надирова. В работе рассматриваются основные направления его исследований в области татарской фольклористики.

**Ключевые слова:** татарская фольклористика, татарское народное творчество, Ильбарис Надиров, татарские народные песни, фольклор периода Великой Отечественной войны.

The article is devoted to the analysis of scientific and scientific-organizational activities of the Honored Worker of Culture of Tatarstan, Laureate of the Gabdulla Tukai State Prize of the Republic of Tatarstan, folklore scientist I.N. Nadirov. The paper examines the main directions of his research in the field of Tatar folklore.

**Keywords:** Tatar folklore, Tatar folk art, Ilbaris Nadirov, Tatar folk songs, folklore of the Great Patriotic War period.

Татар халык иҗатын, аерым алганда җырларны аеруча җентекләп һәм нечкәләп өйрәнгән, алардагы хис байлыгын, шигъриятне, рухи сафлыкны һәм фәлсәфи тирәнлекне ачып, аңлатып бирүгә аеруча зур өлеш керткән фольклорчы галим, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Илбарис Надировның тууына 100 ел тулды. Татар фольклористикасы фәне өлкәсендәге тикшеренүләрнең һәм гомумән фәнни эшләрнең оештыручысы булган бу киң эрудицияле, максатчан шәхеснең тормышы һәм иҗаты аерым игътибарга лаек.

Илбарис Нурислам улы Надиров 1925 елның 15 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Нәдер авылында туа. Озакламый аларның гаиләсе Ютазы районындагы Алмата авылына күченеп килә. Балачак елларында бер авылдан икенче авылга, җырлый-җырлый, Сабан туйларына йөргән чаклары, ул җырларның һаман күңелдә саклануы, булачак галимнең төп шөгыленә – татар җырларын җыю, аларны төрләргә бүлү һәм халкыбызга җыр жанрының үзенчәлекләрен ачып бирүгә олы этәргеч булгандыр.

И. Надиров 1932–1943 елларда башлангыч мәктәпне Ютазы районының Алмата авылында, урта мәктәпне Кәрәкәшле авылында мактау грамотасы белән тәмамлап, район Башкарма комитетында нархозучет инспекторы булып эшли башлый.

Ул Ютазы районы комсомол комитеты юлламасы белән Уфа авиация институтына укырга керә, 1943 елны Чкалов өлкәсенең (хәзерге

Оренбург) Колтубанка төбәгендә урнашкан снайперлар мәктәбендә белем ала, көзен фронтка китә. 1944 елның августыннан башлап, сугыш беткәнче, Балтыйк буе фронтында хезмәт итә, ике тапкыр яралана. Җиңү бәйрәмен 1489 нчы үзйөрешле артиллерия полкында радиотелеграфист буларак каршылый. 1948 елның февралендә, демобилизациянеп, Ютазы районы Алмата авылына әти-әнисе янына кайта. Егетнең укырга, белем алырга теләге зур була. Радиотелеграфист дусты Анатолий Шикуновның: «Иптәш Надиров, ... син белгәнем җитәр дип туктарга уйлыйсың кебек... Төпле белем алу өчен, университет бетерергә кирәк...», – дигән сүзләре һәм киңәше дә йогынты ясый. Ул 1948–1953 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укып, аны кызыл диплом белән тәмамлый.

И. Надиров СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) «фольклористика» белгечлеге буенча филология фәннәре докторы, олуг галим Хәмит Ярми җитәкчелегендә аспирантура уза. Ул беренчеләрдән булып Бөек Ватан сугышы чоры татар халык иҗатын өйрәнә һәм 1959 елда «Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Сугыш чоры фольклорын җентекләп өйрәнүе, билгеле, галимнең биографиясе белән бәйләнгән.

1961 елда галимнең диссертациясе нигезендә «Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты» монографиясе дөнья күрә. Бу китап Бөек Ватан сугышы елларында татар халкы иҗат иткән әсәрләрне җыю һәм өйрәнү өлкәсендә беренче җитди адым була. Китапта сүз Бөек Ватан сугышы чоры татар халык иҗаты әсәрләренең фронтта иҗат ителүе һәм сугышта – солдатлар, ә тылда гади эшчеләр һәм колхозчылар арасында таралу, халык телендә яшәү үзенчәлекләре турында. Монографиянең төп өлешен сугыш чоры фольклорының идея-тематик эчтәлеген өйрәнү алып тора. Совет патриотизмы, дошманнарга каршы аяусыз көрәш, фронтта батырлык, тылдагы фидакяр хезмәт – бу чор халык иҗатында яңгыраган иң көчле фикер. Автор авыр шартларда иҗат ителеп, халык арасында киң таралган фольклор әсәрләренең әдәби-эстетик үзенчәлекләрен дә тикшерә. Аның «Бөек Ватан сугышы елларында халык җырлары» (1957), «Совет армиясе турында татар халык җырлары» (1958), «Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты» (1959), «Сугыш чоры бәетләре» (1960) кебек мәкаләләре бер-бер артлы дөнья күрә. Бу темага И. Надиров вакытлы матбугат битләрендә дә күп кенә мәкаләләр белән чыгыш ясый. Аларда совет чорында яңа фольклор әсәрләре: җырлар, бәетләр туу, аларның шигъри үзенчәлекләре кебек теоретик яктан да әһәмиятле мәсьәләләр яктыртыла [4: 22].

И. Надиров – гомерен халкыбызның җырларын җыюга, фәнни яктан өйрәнүгә, бастырып чыгаруга багышлаган галим. Аның бу өлкәдәге казанышы итеп, 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» дигән җыентыкны күрсәтергә була [6: 2]. Әлеге китап татар

фольклористикасы тормышында мөһим вакыйга булып, халкыбызның җырларын җыю һәм өйрәнү тарихында өр-яңа бер сәхифә ача. Аңа кадәр беркайда да басылмаган 400 артык лирик озын җырларны һәм йола җырларын туплаган әлеге басма фәнни әйләнешкә яңа сыйфатлы фактик материал алып килә. Галим Х. Мәхмүтов билгеләп үткәнчә, «элеккеге елларда татар халкының җыр иҗаты нигезендә дүртьюллык кыска җырлардан тора, дигән караш өстенлек итә иде. И. Надировның үз сүзләре белән әйткәндә, бездә «халыкның ата-бабадан килгән гореф-гадәтләре, гаилә бәйрәмнәре белән бәйле йола поэзиясе» дә, «күңел ачулар, уеннар, биюләр белән тыгыз үрелештә туручы уен җырлары, бию такмаклары» да, «кеше күңелендәге иң тирән кичерешләрне, хисләр хәрәкәтен энҗе кебек бергә тезеп, шигъри бөтенлектә чагылдыручы озын җырлар» да бар. Җыентыкка бирелгән зур күләмле һәм тирән эчтәлекле кереш мәкаләдә И. Надиров, яңа фактик материалларга таянып һәм җырларның көнкүрештә тоткан урынын, йола, уен, биюләр белән бәйләнешен, поэтик үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны дүрт төркемгә бүлә: «йола җырлары», «уен-бию җырлары», «лирик кыска җырлар», «лирик озын җырлар» [4: 21]. Әлеге классификация бу өлкәдә алга таба үткәрелгән тикшеренүләрнең нигезенә ята һәм бүген дә үзенең фәнни әһәмиятен саклап кала.

1960–1970 елларда фольклористика фәнендә җитди бер юнәлеш ачылып, төрле халыклар авыз иҗатының күптомлы басмаларын чыгару эше башлана. Казах, кыргыз, үзбәк, мордва, башкорт һәм башка халыкларда шул юнәлештә беренче җитди адымнар ясала [1: 13]. 1972 елда Институтның халык иҗаты секторы мөдире итеп билгеләнгән И. Надиров әнә шундый күптомлыкның проспектын төзү белән җитәкчелек итә. Әлеге эшне татар фольклористикасы үсешендә яңа бер этап дип билгеләргә була. 12 томлы «Татар халык иҗаты» җыелмасының тәфсилле һәм чын фәнни нигездә әзерләнгән проспекты төзелеп беткәч, сектор галимнәре күптомлыкны әзерләү эшенә керешә. Шушы зур җитди басманың фәнни җитәкчесе булудан тыш, И. Надиров – дүрт томның турыдан-туры төзүчесе, кереш мәкаләләр һәм искәрмәләр авторы. Ул төзегән «Кыска җырлар» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Бәетләр» (1983), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) томнары халык иҗатын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Шушы уникетомлыкны әзерләүгә куйган хезмәтләре өчен галимгә (тагын берничә хезмәттәше белән бергә) Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

И. Надировның Мәскәү, Ленинград, Казан, Тбилиси, Алматы, Кишинёв һәм башка шәһәрләрдә уздырылган бөтенсоюз фольклор киңәшмәләрендә проблемалы докладлар белән катнашуын, фәннилештыру эшләренә, яшь белгечләр хәзерләүгә күп көч куюын әйтми калу мөмкин түгел. Ун ел дәвамында ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми сәркатибе һәм директор урынбасары булып эшли, егерме елга якын биредә халык иҗаты бүлеген җитәкли.

И. Надиров бүлек мөдире булып эшләгән чорда татар фольклорының төрле проблемаларына караган җиде фәнни җыентык дөнья күрә. Мәсәлән, «Татар фольклоры жанрлары», «Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре», «Татар фольклорында социаль мотивлар», «Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы», «Поэтика татарского фольклора» һ.б. Идел-Урал буенда яшәүче халыклар фольклорындагы үзара бәйләнешләргә багышланган региональ симпозиум үткәрелә. Галим татар фольклоры буенча белгечләр әзерләүгә дә зур игътибар бирә. Ул дүрт аспирантка җитәкче була, һәм бүгенге көндә алар барысы да – татар фольклористикасы үсешенә өлеш керткән галимнәр.

И. Надиров шулай ук чит илләрдә яшәгән татар диаспоралары белән бәйләнешләрнең беренче эзләрен салыша. Финляндиягә татар галимнәре, артистларының тәүге сәфәрен оештыруда, чит илдә яшәүче милләттәшләребезне Казанда кабул итүдә И. Надировның роле зур булды. Шуның белән бергә, галим – татар фольклор фәненә зур хезмәт күрсәткән аерым шәхесләр һәм Финляндиядәге татар диаспорасы турындагы мәкаләләр авторы да. Болар барысы да аның киң кырлы шәхес, оста оештыручы булуын тагын бер мәртәбә раслый.

Шулай итеп, Илбарис ага Надиров – Бөек Ватан сугышы чорындагы татар халык иҗатын беренчеләрдән булып өйрәнгән галим. Шул ук вакытта ул үзенең бөтен көчен, сәләтен, гомерен аңа җан рәхәте биргән татар халык иҗатын – җыр жанрын өйрәнүгә багышлаган. Аның хезмәтләре яши һәм бүген дә үз халкына хезмәт итүдән туктамый.

**Әдәбият**

1. *Мәхмүтов Х.Ш.* Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 223 б.

2. Татарский энциклопедический словарь. Казань, 1999. С. 383.

3. Утлы еллар кайтавазы: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 199 б.

4. Фәнни эзләнүләр юлында. Казан: Фикер, 2000. 288 б.

5. *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с.

6. *Ямалтдинов И.И.* XX йөзнең 60 нчы елларында халык авыз иҗаты буенча тикшеренүләр // Фәнни Татарстан. 2024. № 3 (43). Б. 103–106.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Ямалтдинов Ильмир Ильдарович,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*jailmir@mail.ru*